| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**30.01.2020** Казан шәһәре **№ 13**

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Товарларга (эшләргә, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес булу-булмавына һәм аларның күләменең нигезле булу-булмавына контрольлек чараларын уздырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында җәлеп ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә һәм Товарларга (эшләргә, хезмәтләр күрсәтүгә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес булу-булмавына контрольлек өлкәсендә экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 8 декабрендәге 391 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) «Товарларга (эшләргә, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес булу-булмавына һәм аларның күләменең нигезле булу-булмавына контрольлек чараларын уздырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында җәлеп

ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә һәм Товарларга (эшләргә, хезмәтләр күрсәтүгә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес булу-булмавына контрольлек өлкәсендә экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 8 декабрендәге 391 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында җәлеп ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә һәм Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздыруга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителә торган экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен раслау турында»;

боерыкның беренче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Расларга:

Әлеге боерыкның 1 нче кушымтасына туры китереп, Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында җәлеп ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә).

Әлеге боерыкның 2 нче кушымтасына туры китереп, Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздыруга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителә торган экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен.».

2. Әлеге боерык белән расланган Товарларга (эшләргә, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес булу-булмавына һәм аларның күләменең нигезле булу-булмавына контрольлек чараларын уздырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында җәлеп ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында җәлеп ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә»;

1.1-1.2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздырганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында җәлеп ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә экспертлар сыйфатында гражданнарны аттестацияләү өчен төзелә.

1.2. Нигезләмә Комиссиянең эш тәртибен билгели.»;

3.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын үткәрүгә Дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителә торган, эксперт статусы алуга дәгъва белдерүче гражданнар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

Нигезләмәнең 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Нигезләмәнең 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3. Әлеге боерык белән расланган Товарларга (эшләргә, хезмәтләр күрсәтүгә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес булу-булмавына контрольлек өлкәсендә экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздыруга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителә торган экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Әлеге Кагыйдәләр Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздыруга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителә торган экспертлар реестрын (алга таба – Реестр) формалаштыру һәм алып бару тәртибен, шул исәптән Реестрга кертелә торган белешмәләрнең составын һәм Реестрдан белешмәләр бирү тәртибен билгели.»;

1.2 пунктта «административ практика бүлеге» сүзләрен «контроль-ревизия бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

5. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары С.В.Павловка йөкләргә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2014 елның 8 декабрендәге 391 номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының __________________ № ________ боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан экспертлар сыйфатында контрольлек чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган гражданнарны аттестацияләү комиссиясе утырышының _________ номерлы беркетмәсе

________________
(дата)

Комиссия, түбәндәгеләр составында:
Комиссия рәисе: ________________________
Комиссия рәисе урынбасары: ________________________
Комиссия әгъзалары: ________________________

дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздыруга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларга кандидатлар арасында квалификация имтиханын уздырды:

| Тәртип саны | Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Экспертиза төре | Имтихан нәтиҗәләре (аттестация критерийларына туры килә/аттестация критерийларына туры килми) |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Комиссия рәисе ____________________________________
(имза) (тулы имза)

Комиссия рәисе урынбасары ____________________________________
(имза) (тулы имза)

Комиссия секретаре ____________________________________
(имза) (тулы имза)

Комиссия әгъзалары ____________________________________
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2014 елның 8 декабрендәге 391 номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ________________ № _______ боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитеты Рәисенә
_______________________________
кемнән_______________________________
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, ата исеме, туган көне)
_______________________________
(ИНН)
_______________________________
(шәхесне раслаучы документ белешмәләре)
_______________________________
(яшәгән урын адресы)
_______________________________
(телефон номеры, электрон почта адресы)

Экспертны аттестацияләү турында
гариза

Дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздыруга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителә торган эксперт сыйфатында аттестация уздыру турында үтенәм.

Кушымталар:

- белем алуны раслаучы документларның күчермәләре, шулай ук (булганда) гыйльми дәрәҗә булуын раслаучы документларның күчермәләре, аттестатларның, сертификатларның, таныклыкларның күчермәләре;

- хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

- кандидатның билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендәге экспертизаларда катнашуын раслый торган һәм эксперт эшчәнлеген башкару сәләтен бәяләргә мөмкинлек бирә торган (булган очракта) документларның күчермәләре.

_______________________________ (дата)

_______________________________ (гариза бирүченең имзасы)